МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ
ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ
ШКОЛА №12» г. АЛЬМЕТЬЕВСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. М. Джалиля , д,41, г. Альметьевск, 423450

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕНЕҢ "12НЧЕ УРТА ГОМУМИ
БЕЛЕМ БИРУ МӘКТӘБЕ" МУНИЦИПАЛЬ
БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРУ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ
Җәлиль ур.,41нче йорт, Әлмәт шәһәре,423450

Тел.8(8553) 32-73-73,32-72-72 факс 8(8553) 32-73-73, e-mail: Shkola -12.Alm@tatar.ru. сайт:edu.tatar.ru/almet/sch12

# П Р И К А З № 304

**"О внесении изменений в основную образовательную программу начального общего образования, в основную образовательную программу основного общего образования, в основную образовательную программу среднего общего образования"** **от 23.10.2017**

В связи с введением в учебный план начального общего образования учебного предмета «Родной язык и литературное чтение», в учебный план основного общего образования учебного предмета «Родной язык и литература», «Родной язык и родная литература», в учебный план среднего общего образования учебного предмета «Родной язык»

**ПРИКАЗЫВАЮ:**

1. Считать утратившими силу:

1.1. п.п. 1.2.4 Татарский язык и литературное чтение (для татароязычных), 1.2.5. Татарский язык и литературное чтение (для русскоязычных) Целевого раздела основной образовательной программы начального общего образования; п.2.2.2.3. Татарский язык, п. 2.2.2.4. Литературное чтение (тат) Содержательного раздела основной образовательной программы начального общего образования.

1.2. п.п. 1.2.2.3. Татарский язык, п.п. 1.2.2.4. Татарска литература обязательного минимума содержания основных образовательных программ основного общего образования в соответствии с Федеральным компонентом государственного образовательного стандарта.

1.3. п.п. 1.2.5.3. Татарский язык и литература/Татар теле һәм әдәбияты Целевого раздела основной образовательной программы основного общего образования (ФК ГОС), п.п. 2.3. Татарский язык, п.п. 2.4. Татарская литература Содержательного раздела основной образовательной программы основного общего образования (ФК ГОС);

1.4. п.п. 4.3. По татарскому языку, п.п. 4.4 По татарской литературе обязательного минимума содержания основных образовательных программ среднего общего образования в соответствии с Федеральным компонентом государственного образовательного стандарта

2. Внести изменения:

2.1. п.п. 1.2.4 Родной (татарский) язык и литературное чтение, 1.2.5. Родной (русский) язык и литературное чтение Целевого раздела основной образовательной программы начального общего образования (Приложение №1);

2.2. п.п. 1.2.2.3. Родной язык и литература, обязательного минимума содержания основных образовательных программ основного общего образования в соответствии с Федеральным компонентом государственного образовательного стандарта (Приложение №4);

2.3. п.п. 1.2.5.3. Родной язык и литература Целевого раздела основной образовательной программы основного общего образования (ФГОС), п.п. 2.3. Родной язык и литература

Содержательного раздела основной образовательной программы основного общего образования отдельных учебных предметов основной образовательной программы основного общего образования (ФГОС) (Приложение №2);

2.4. п.п. 4.3. По родному языку и родной литературе обязательного минимума содержания основных образовательных программ среднего общего образования в соответствии с Федеральным компонентом государственного образовательного стандарта. (Приложение №3).

3. Учителям-предметникам, у которых произошли изменения в учебных планах, привести рабочие программы в соответствии с нормативными правовыми документами школы (срок до 26.10.2017г.).
4. Учителям родного языка и литературы разработать рабочие программы по соответствующим предметам и представить на утверждение (срок до 26.10.2017г.)
5. Контроль над исполнением настоящего приказа оставляю за собой.

**Директор МБОУ «СОШ №12»:** **Н.А. Калинина**

Приложение 1

## 1.2.4. Родной язык (татарский) и литературное чтение

### Русская группа

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – **системалы-эшчәнлекле (системно-деятельностный подход) юнәлеш,** ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән рус телле балаларга татар теле укыту системасына да карый. Ягъни, рус телле балаларга туган тел укыту системасының барлык **компонентлары** да: программалар, укыту-методик комплектлары, укыту процессы, белем дәрәҗәсенә контроль, идарә итү, белем күтәрү һ.б. – бар да бер максатка – **нәтиҗәгә** хезмәт итә.

Тәкъдим ителгән "Гомуми белем бирү мәктәпләрендә рус телле балаларга туган телне коммуникатив технология нигездә укыту программасы" психология, педагогика фәннәренең яңа казанышларына таянган һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология нигезендә укыту принципларын исәпкә алып төзелде.

Әлеге программа рус телле балаларга туган тел укыту буенча **эш программаларын** төзү өчен нигез булып тора. Ул укыту предметының мәҗбүри өлешен билгеләгән төп программага таянып төзелде. Укытучылар **эш программаларына** мәктәпнең эш үзенчәлеген, укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку материалын өйрәнүгә **сәгатьләр саны бүленешен** һәм материалны **өйрәнү эзлеклелеген билгеләүдә, эчтәлекне киңәйтүдә,** шулай ук укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру юлларын ачыклауда **үзгәрешләр** кертә алалар. Бу үзгәрешләр эш программаларының **аңлатма язуында** чагылыш табарга тиеш.

Программа дәүләт контроле һәм белем сыйфатын билгеләү системасы өчен нигез булып тора.

### УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНА ГОМУМИ АҢЛАТМА

**1)Туган тел һәм әдәби уку (татар телендә) укыту максатлары.**

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга туган тел укыту **максатлары** берничә аспектны үз эченә ала: **танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.**

*Танып белү максатының эчтәлеге*

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен "башка дөньяга тәрәзә ачу" булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, Татарстанның территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча күренекле шәхесләр турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

*Үстерү максатының эчтәлеге*

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында **үстерү, тәрбия максатларын** даими күзаллап эшләү – укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты. Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

– хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисселек, эмпатия хисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

Бу максатлар программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда да беренче планга куела.

*Тәрбияви максатның эчтәлеге*

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу мөһим. Туган телнең грамматикасын өйрәнү процессында эчтәлектә әхлакый проблемалар булган кечкенә текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, ягъни, укучыларның эчке кызыксынуы тәэмин ителгән була.

үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, ягъни, укучыларның эчке кызыксынуы тәэмин ителгән була. Шунлыктан тексттагы лексика, грамматика җайлырак истә кала һәм аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый.

*Белем бирү максатының эчтәлеге*

Укучыларның туган тел буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Укучының белеме дигәндә, без аның аерым сүзләрне яки грамматик категорияне тану, аера белүен генә күзалламыйбыз, ә аларны кулланып сөйләшә алуын күзаллыйбыз. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**2) Коммуникатив технология нигезендә төзелгән программага эчтәлек сайлау принциплары.**

Программа Федераль Дәүләт стандартларының методологик нигезе булган **системалы-эшчәнлекле юнәлешкә туры килә торган коммуникатив технологияне** төп укыту ысулы буларак билгели.

Коммуникатив технология нигезендә укыту процессын оештыру өчен, бу технология билгеләгән максатларга һәм принципларга туры килгән программа эчтәлеген сайлау таләп ителә. Димәк, коммуникатив технология нигезендә укыту принципларнын ачыклау – программа эчтәлеген сайлау өчен төп критерийлар, норматив база булып тора.

*1. Телне аралашу аша өйрәнү принцибы*

Атаклы психологлар А.Н. Леонтьев, П.Я. Гальперин хезмәтләре күрсәтүенчә, белемнәрне үзләштерү аларны нинди дә булса эшчәнлектә куллану аша бара. Башта белемнәр суммасы булдырып, аннан соң аны практикада кулланырга мөмкин дип уйлау хәзерге дидактик таләпләргә җавап бирми. Сөйләмгә өйрәтү процессы башта аерым сүзләр, грамматик категорияләр өйрәнеп, аннан шулар нигезендә сөйләм оештыру аша барса, бу бик әйләнгеч, нәтиҗәсез юл булыр иде. Коммуникатив технология нигезендә эчтәлек сайлау стратегиясе һәм тактикасы түбәндәгедән гыйбарәт була: башта балаларның яшь үзенчәлегенә карап, аларның аралашу сфералары, аралашу ситуацияләре ачыклана, аннан соң ул сфераларда сөйләшүне оештыра алырлык лингвистик материал сайлана. Бу процесс түбәндәге схемада күрсәтелә:

**Лингвистик материал сайлау схемасы**

**Социаль контактлар, аралашу сфералары, ситуацияләрне ачыклау→Сөйләшү, сөйләм предметын билгеләү→Сөйләм бурычларын ачыклау→Тиешле лингвистик материалны сайлау.**

Сайлап алынган лингвистик материал филологик формада таныштыргач, аны төрле аралашу сфераларындагы социаль контактларда, аралашу ситуацияләрендә, текстлар эчтәлеген сөйләүдә куллану камилләштерелә. Өйрәнелгән грамматик материал максатчан рәвештә төрле жанрдагы текстлар эчтәлегендә кулланылып, укучыларның сөйләшә алулары камилләштерелә.

Югарыда әйтелгәннәрне искә алып сайланган материал мәктәптә телгә өйрәтү шартларын телне тормышта куллану шартларына якынлаштыру мөмкинлеген тудыра.

*2. Уку процессын индивидуальләштерү принцибы*

Россия Федерациясенең мәгарифне үстерү доктринасында күрсәтелгәнчә, хәзерге заман белем бирү системасы үсешенең төп юнәлеше – укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру.

Башлангыч сыйныф укучылары эмоциональ, хәрәкәтчән, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә, кабул итә һәм фикерли башлый. Күрсәтелгән психологик үзенчәлекләрнең, һичшиксез, эчтәлек сайлаганда исәпкә алынуы зарур.

Башлангыч сыйныфларда укыту процессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану – лингвистик материалны өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Ассызыклап шуны әйтергә кирәктер, өйрәнелгән лексик-грамматик материал балаларның социаль контактларына туры килеп, аларның татарча аралашуын тәэмин итәрлек булырга тиеш. Әлбәттә, укучыларның психофизиологик мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур.

Урта һәм югары сыйныф укучылары өчен программада эчтәлек әхлакый проблемалар тирәсенә туплана. Әйтик, “Белем һәм тормыш” темасында “Яхшы уку өчен, нинди сыйфатлар кирәк?” “Яхшы уку җиңелме?“ проблемалары буенча сөйләшү оештырыла. Аңлашыла: бу әхлакый проблемалар, нигездә, балаларның тормыштагы төрле мөнәсәбәтләрен чагылдыра. Шунлыктан, укучыларда бу мөнәсәбәтләргә карата үз фикерләрен әйтү, димәк, сөйләшергә теләү ихтыяҗы туа. Укучы, укытучы кушканга түгел, ә үз теләге, үз ихтыяры белән сөйләм эшчәнлегенә тартыла.

*3. Телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү принцибы*

Белем алу процессын укучыларның актив фикерләвенә нигезләп оештыру психология һәм педагогика фәннәренең алдынгы вәкилләре куйган төп таләпләрнең берсе. Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм

бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнү өчен күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүр. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуы тәэмин ителә. Шуңа күрә программада һәр сыйныфта аралашу өчен коммуникатив максатлар, өлкән сыйныфларда аралашу проблемалары күрсәтелеп барды. Лингвистик материал һәм сөйләм үрнәкләре программада нәкъ менә коммуникатив максаттан, аралашу проблемаларыннан чыгып билгеләнде.

*4. Телне функциональ төстә өйрәнү принцибы*

Коммуникатив методикага беренче нигез салучылардан булган Э.П. Шубин мәктәптә чит телне өйрәтү процессында грамматик материалны академик грамматика эзлеклелегендә һәм тирәнлегендә өйрәнүне мәҗбүр итеп куймый. Функциональ принцип нигезендә программага грамматик материал түбәндәге таләпләр буенча сайлана:

- грамматик материал коммуникатив максаттан, аралашу хаҗәтеннән һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнә;

– грамматик материалның өйрәнелү тәртибе академик бирелештә түгел, аралашу хаҗәтеннән һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнә;

- грамматик материалның күләме, теоретик авырлыгы укучыларның үзләштерү мөмкинлекләрен исәпкә ала;

- грамматика, тел берәмлеге буларак түгел, ә сөйләм берәмлеге буларак өйрәнелә; иң беренче чиратта, грамматик категориянең формасына түгел, ә аның функциясенә игътибар ителә: хәбәр итү, аңлату, сорау, тәкъдим итү, киңәш бирү, ышандыру һ.б.

Башлангыч этап өчен грамматик материал күрсәтелгән критерийларга таянып сайланды. Берникадәр грамматик материал теоретик формада бирелмичә, ә лексик-грамматик төзелмәләр формасында тәкъдим ителде. Аларны үзләштерү сөйләм ситуцияләре нигезендә оештырыла. Ә җиңелрәк дип саналган грамматик материал филологик формада, кагыйдәләр нигезендә өйрәнелә бара. Ләкин кагыйдәләрне ятлау мәҗбүр түгел, ә лексик-грамматик материалны күбрәк аралашуда имитацияләүгә игътибар ителә.

Урта һәм югары сыйныфларда – грамматик материал, нигездә, филологик формада, грамматик кагыйдәләр нигезендә тәкъдим ителде.

*5. Ана телен исәпкә алу принцибы*

Икенче телне өйрәнү вакытында бала, ихтыярсыз рәвештә, лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу – телне үзләштерү процессын җиңеләйтә. Димәк, һәр сыйныфка программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур. Яңа грамматик кагыйдәләр бары тик ана телендә өйрәнелгәннән соң гына кертелә бара, ә дәреслекләрдә грамматик кагыйдәләрнең рус һәм татар телләрендә бирелүе укучыларның белем сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора.

## УКЫТУНЫҢ ГОМУМИ, ШӘХСИ, МЕТАПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятkә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Туган тел өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни, татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;

– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, киң күнелле әңгәмәдәш булу;

– “Туган тел” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм, шулар нигезендә, белем алуның алдагы баскычларында туган тел уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

– текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

– “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре:**

Урта белем бирү баскычында туган тел укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Туган тел укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни, төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә; укучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

– уку хезмәтендә үзенә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
– әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Укытуның башлангыч этабы**

**Тыңлап аңлау**

Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау; тыңлаганда җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру; сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү; сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү; ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

**Диалогик сөйләм:**

Өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү; программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына җавап бирү һәм сораулар куя белү; дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм**

Җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү; тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә

төрләрен файдаланып, хикәя төзү; укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү; үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә мәгълүмат бирә белү.

**Уку**

Татар алфавитындагы хәрефләрне таный белү; хәреф-аваз системасын аера, туган телгә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү; дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү; тексттагы тыныш билгеләренә карап, тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү, өтерләр янындагы сүзләрне тыңдашлек, эндәшү интонацияләре белән уку; укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү; кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү; укыганд,а сүзлекләр куллана белү.

**Язу**

Татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү; дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру; бәйрәмнәр белән котлау, чакыру кәгазьләре язу; конверт һәм дәфтәр тышына яза белү; программада күрсәтелгән темалар буенча, терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру.

**Программаның тематик эчтәлеге**

**1 нче сыйныф**

| **Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны** | **Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат,** |
|---|---|
| **Әйдәгез танышабыз!**<br>Танышу. Бер-береңнең исемен сорау, яшәү урынын әйтү. 1дән 10га кадәр саннар. | Әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, хәлен сорый белү. Әңгәмәдәшеңнең яшәү урынын сорый һәм үзеңнең кайда яшәвең турында хәбәр итә белү.<br>Бер-береңнең яшен, ничәнче сыйныфта укуын сорый, җавап бирә белү. Бергә уйнарга чакыра белү. |
| **Йорт хайваннары һәм кошлары, кыргый** хайваннар, аларның исемнәре, яшәү<br>урыннары. Аларны сурәтләү. | Кыргый хайваннарның кайда яшәгәнен әйтә, аларны сурәтли белү. |
| **Спорт бәйрәме**<br>Без команда бирәбез. Спорт бәйрәмендә катнашу. | Иптәшеңә командалар бирә белү. Спорт бәйрәмендә нишләгәнеңне әйтә белү. Дустыңны уйнарга чакыра, кем белән уйнаганыңны әйтә белү. |
| **Мәктәптә**<br>Уку-язу әсбаплары. Уку-язу әсбапларының саны, төсе, барлыгы, юклыгы. Мәктәптә уку хезмәте. Мин ничек укыйм? | Уку-язу әсбапларының исемнәрен әйтә, үзеңә сорап ала, иптәшеңә тәкъдим итә, кирәклеген, санын әйтә белү. Мәктәптәге уку хезмәтен атый, үзеңнең, иптәшеңнең ничек укуын әйтә белү. Предметларның урынын әйтә белү (китап өстәлдә) |
| **Йорт хайваннары һәм кошлары**<br>Йорт хайваннары һәм кошлары, аларның исемнәре, яшәү урыннары. Аларны сурәтләү. | Йорт хайваннарының һәм кошларының исемнәрен әйтә, саный, яшәү урынын әйтә белү |
| **Бакчада**<br>Яшелчә исемнәре, саны, аларның төсе, тәме. Җиләк-җимешләр, саны, аларның төсе, тәме. | Яшелчә һәм җиләк-җимеш исемнәрен, санын, аларның төсен, тәмен әйтә, аларны сорап ала белү. Бакчада нәрсә үскәнен, нинди эшләр эшләгәнеңне әйтә белү.<br>Нәрсә яратканыңны, яратмаганыңны әйтә, сорый белү.<br>Хезмәтенә карап, геройга бәя бирә белү. |
| **Кыш җитте**<br>Кыш билгеләре. Кышкы уеннар. Яңа ел бәйрәме. | Кыш билгеләрен әйтә, сорый, һава торышын тасвирлый белү. Яңа ел бәйрәме турында сөйли белү. Бәйрәмгә барганыңны, бәйрәмнең кайда булганын әйтә белү. Кышкы уен төрләрен әйтә, уенга чакыра белү. Чана, чаңгы, тимераякларның барлыгын, юклыгын, нәрсә белән шуганыңны әйтә белү. |

| | |
|---|---|
| **Сәламәт бул**<br>Тән әгъзаларының исемнәре. Табиптә. Шәхси гигиена предметлары. | Тән әгъзаларының исемнәрен атый, кайсы җирең авыртканын сорый, әйтә белү. Сәламәт булу өчен, киңәшләр бирә белү. Авыру кешенең хәлен сорау, аңа дару, чәй тәкъдим итә белү. Шәхси гигиена предметларының исемнәрен, аларның барлыгын, юклыгын, кирәклеген әйтә, аларны сорап ала белү. |
| **Гаилә, өйдә булышу**<br>Гаилә әгъзалары. Без гаиләдә нишлибез? 8нче Март – әниләр бәйрәме. Язгы көн. | Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, үз гаиләң турында сөйли белү, иптәшеңнең гаиләсе турында сорый белү. Язгы көнне сурәтләп сөйли белү. Яз фасылының ошаганын, ошамаганын әйтә белү. Бәйрәм белән котлый, кемгә бүләк бирүне әйтә белү. |
| **Кибеттә**<br>Ашамлыклар. Ашамлыклар кибетендә. Савыт-сабалар. Савыт-саба кибетендә. Киемнәр. Киемнәр кибетендә. | Ашамлыклар исемнәрен,нәрсә ашаганыңны, эчкәнеңне әйтә, кибеттә сатып ала белү. Савыт-саба исемнәрен дөрес әйтә белү. Киемнәрнең исемен, төсен, нинди кием кигәнеңне әйтә белү. |
| **Без шәһәрдә яшибез**<br>Шәһәрдә. Безнең шәһәр. Мин транспортта барам. | Нинди республикада яшәгәнеңне, Татарстан шәһәрләре исемнәрен әйтә белү. Нинди транспортта барганыңны әйтә белү. |
| **Җәй**<br>Күңелле җәй. Җәйге ял. Без Сабантуйга барабыз. | Җәй билгеләрен әйтә белү. Дусларны Сабантуй бәйрәменә чакыра, бәйрәмдә нишләгәнеңне әйтә белү. |

**1нче сыйныф**

1. Исемнәрнең берлек һәм күплек саны.
2. Исемнәргә **кем? нәрсә?** сорауларын куя белү.
3. Исемнәрнең 1, 2,3 нче затта берлектә тартым белән төрләнеше белән таныштыру.
4. Исемнәрнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләре белән таныштыру.
5. Микъдар һәм тәртип саннары белән таныштыру (1-10 саннары).
6. Зат алмашлыкларын берлектә баш, иялек, юнәлеш килешләрендә сөйләмдә куллану .
7. **Бу** күрсәтү алмашлыгын сөйләмдә куллану.
8. **Кая? Кайда? Кайдан?** сорауларына җавап бирә белү.
9. **Ничә? Ничек?Нинди?** сорауларына җавап бирә белү.
10. Хәзерге заман хикәя фигыльнең 1,2,3 зат формаларын берлектә сөйләмдә куллану.
11. Боерык фигыльнең II затта берлек сан формасы белән таныштыру.
12. **-мы/-ме, түгел, әле** кисәкчәләрен сөйләмдә куллану.
13. **Белән** бәйлеген исем белән сөйләмдә куллану.
14. **Һәм** теркәгечен сөйләмдә куллану.
15. **Сыйфат+исем** төзелмәсен сөйләмдә куллану.
16. **Сан+исем** төзелмәсен сөйләмдә куллану.

**Орфографик һәм орфоэпик минимум.**

Сузык һәм тартык авазлар, аларның аермасы. Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аерырга өйрәнү.

Татар һәм рус телләрендәге сузык һәм тартык авазларны чагыштырып, дөрес әйтә белү, транскрипция билгеләре белән таныштыру.

Сүзләрне иҗекләргә бүлү, иҗекләп икенче юлга күчерү. Иҗек калыпларына нигезләнгән уку кагыйдәләрен гамәли үзләштерү.

Озын һәм кыска сузыкларны сүзләрдә дөрес итеп әйтә белү.

Татар хәрефләренең кабул ителгән формаларын дөрес язу.

Сүз басымы. Сүзләрдә басымны дөрес кую.

Хикәя һәм сорау җөмләләрне интонацион яктан дөрес әйтергә гадәтләндерү. Җөмлә ахырында дөрес тыныш билгеләрен куеп язарга күнектерү.

Ялгызлык исемнәрен баш хәрефтән башлап язарга өйрәнү.

Матур һәм дөрес язу күнекмәләре булдыру.

Әйтү максаты белән әйтелгән җөмләләрне аңларга өйрәнү

Сузык һәм тартык авазлар, аларның аермасы. Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аерырга өйрәнү.
Татар һәм рус телләрендәге сузык һәм тартык авазларны чагыштырып, дөрес әйтә белү, транскрипция билгеләре белән таныштыру.
Сүзләрне иҗекләргә бүлү, иҗекләп икенче юлга күчерү. Иҗек калыпларына нигезләнгән уку кагыйдәләрен гамәли үзләштерү.
Озын һәм кыска сузыкларны сүзләрдә дөрес итеп әйтә белү.
Татар хәрефләренең кабул ителгән формаларын дөрес язу.
Сүз басымы. Сүзләрдә басымны дөрес кую.
Хикәя һәм сорау җөмләләрне интонацион яктан дөрес әйтергә гадәтләндерү. Җөмлә ахырында дөрес тыныш билгеләрен куеп язарга күнектерү.
Ялгызлык исемнәрен баш хәрефтән башлап язарга өйрәнү.
Матур һәм дөрес язу күнекмәләре булдыру.
Боеру максаты белән әйтелгән җөмләләрне аңларга өйрәнү.

**2нче сыйныф**

| **Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны** | **Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат,** |
|---|---|
| **Без мәктәпкә барабыз**<br>Беренче сентябрь. Уку-язу әсбапларының барлыгы, юклыгы, кирәклеге. Уку хезмәте. | Беренче сентябрь турында сөйли, укытучыны, дустыңны бәйрәм белән котлый белү. Бер-береңнең ничәнче сыйныфта укуын сорый, җавап бирә белү. Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын, кирәклеген хәбәр итә белү (сорау); үзеңә сорап алу, иптәшеңә тәкдим итә белү. Предметларны, саннар кулланып, үзеңә сорый белү.<br>Бер-береңнең ничәнче сыйныфта укуын сорый һәм җавап бирә белү.<br>Мәктәптәге уку хезмәте турында сорый, сөйли белү, нәрсә эшләгәнне, нәрсә эшләмәгәнне сорый, әйтә белү.<br>Укучының уку хезмәтенә бәя бирә белү. |
| **Базарда.**<br>Яшелчәләр. Җиләк-җимешләр. Базарда. Көз билгеләре. | Яшелчә, җиләк-җимеш исемнәрен, төсен, тәмен, нәрсә яратуыңны әйтә белү. Базарга барырга чакыра, кем белән барганыңны әйтә белү. Базарда яшелчә, җиләк-җимеш сатып ала белү. Көз билгеләрен, көзне яратканыңны, яратмаганыңны әйтә белү. Урамга уйнарга чакыра белү. |
| **Мин чисталык яратам**<br>Шәхси гигиена предметлары.<br>Тән әгъзалары атамалары. Табибта. | Шәхси гигиена предметларының исемнәрен, аларны кулланып, нәрсә эшләгәнеңне әйтә, сорый белү. Тән әгъзаларын атый белү.<br>Табибка кайсы җирең авыртуын әйтә белү. Авыру кешенең хәлен сорау, аңа дару, чәй тәкъдим итә белү. |
| **Кыш җитә**<br>Кыш айлары, кыш билгеләре.<br>Яңа ел бәйрәме. Кышкы уеннар. Кошларга җимлек куябыз. | Кыш айларын атый, кыш билгеләрен әйтә белү. Яңа ел бәйрәмендә нишләгәнне әйтә, Яңа ел бәйрәме белән котлый белү. Яңа ел бәйрәменә чакыра белү. Кышкы уеннарның төрләрен әйтә, уенга чакыра; тауга барганыңны, кайтканыңны, тауда чаңгы шуганыңны әйтә белү. |
| **Гаилә, өйдә булышу**<br>Безнең гаилә. Татар халык ашлары. Өй хезмәте. | Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, гаиләдә кемнәр, ничә кеше барлыгын, кайда эшләгәнен әйтә белү. Татар халык ашларын атый, нинди ашлар пешергәнне белү, бер-береңне табынга чакыра, кыстый, ашаганнан соң рәхмәт әйтә белү. Өй хезмәтендә катнашуыңны әйтә белү. |
| **Яз килә" (10 сәг.)**<br>Яз билгеләре. 8 нче Март – әниләр бәйрәме. | Яз билгеләрен әйтә белү. Урамга уйнарга чакыра, көннең нинди икәнен сорый, әйтә белү. Бәйрәмдә, нинди бүләк биргәнеңне, кемне котлаганыңны әйтә белү. |
| **Туган җирем**<br>Минем туган ягым. Татарстанның табигате. Татарстан шәһәрләре. | Бер-береңнең яшәү урынын сорый һәм кайда яшәгәнеңне әйтә белү. Татарстан шәһәрләренең, елгаларының атамаларын әйтә белү. Нинди транспортта барганыңны әйтә белү. Кайсы шәһәргә барганны сорый белү. Светофорда нинди төсләр барлыгын әйтә, юл йөрү кагыйдәләрен |

| | |
|---|---|
| Мин авылда яшим. | әйтә белү. Авыл табигате турында сөйли белү. Җәйге уен төрләрен әйтә белү. |
| **Кибеттә** | Кием исемнәрен, бәяләрен сорый, нинди кием ятратканыңны әйтә белү. |
| Киемнәр кибетендә.<br>Ашамлыклар кибетендә. | Бер-береңнең киеменә комплимент әйтә белү. Ашамлык исемнәрен, нинди ашамлыклар кирәклеген сорый, әйтә белү. Кибеткә барганыңны һәм нәрсә алганыңны әйтә белү. |
| **Җәй**<br>Җәй җитте. Без Сабантуйга барабыз. | Җәй көне турында сөйли белү. Каникулны ничек үткәрү турында сөйләшү. Урманда җиләк җыйганыңны әйтә белү. |

**2 нче сыйныф**

Исемнең төшем килеше белән таныштыру.

Исемнәрнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләрен сөйләмдә куллануны камилләштерү.

Исемнәрнең берлек санда 1,2 затта тартым белән төрләнешен сөйләмдә куллануны камилләштерү.

Исемнәрнең берлек санда 3 затта тартым белән төрләнеше белән таныштыру (*аның китабы, сумкасы*).

Сыйфатның гади дәрәҗәсен сөйләмдә куллану.

11дән 100 гә кадәр саннарны сөйләмдә куллану.

Мин, син зат алмашлыкларын юнәлеш килешендә сөйләмдә куллану.

Зат алмашлыкларын күплектә сөйләмдә куллану.

**Кайчан?** сорау алмашлыгы белән таныштыру.

**Кем? Нәрсә? кайда? кая? кайдан? нинди? ничек? ничә? ничәнче?** сорауларына җавап бирә, аларны кулланып, сорау бирә белүне камилләштерү.

Хәзерге заман хикәя фигыльнең 1,2,3нче зат юклык формасы белән таныштыру.

Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта берлек сан 1,2,3нче зат формасы белән таныштыру.

Боерык фигыльнең барлык һәм юклык формалары белән таныштыру.

**Кирәк, кирәк түгел, ярый, ярамый** хәбәрлек сүзләрен сөйләмдә куллану.

**Чөнки** теркәгечен сөйләмдә куллану.

**Орфографик һәм орфоэпик минимум.**

Сузык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны дөрес әйтү һәм язу күнекмәләрен камилләштерү. Сингармонизм законы. Татар теленең үзенчәлекле сузыклары һәм аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Сүзләрне транскрипция билгеләре белән яза белү.

Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау авазлар. Алар кергән сүзләрне дөрес әйтә һәм язу күнекмәләрен камилләштерү.

Татар алфавитын яттан белү.

Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Укылган иҗекләр санын билгели белү.

Аралашу өчен бирелгән темаларга караган сүзләрнең дөрес әйтелешенә ирешү.

Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен интонациягә бәйле рәвештә кую

**3 нче сыйныф**

| **Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны** | **Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат,** |
|---|---|
| **Яңа уку елы котлы булсын**<br>Беренче сентябрь – белем бәйрәме. Төсләр. Без диктант язабыз. Без дәрестә. Мин билге алам. Без китапханәгә йөрибез. | Беренче сентябрь – Белем бәйрәме турында сөйли, укытучыны, дустыңны бәйрәм белән котлый белү. Предметларның төсен, санын әйтеп, үзенә сорый белү. Сумкага нәрсә салганыңны, сумкада (партада) нәрсә барлыгын, сумкадан нәрсә алганыңны әйтә, сорый белү. Үзеңнең, иптәшеңнең нинди билге алганын, диктантта нинди хата барлыгын, өй эшен эшләгәнен, эшләмәгәнен, мисал, мәсьәлә чишкәнен сорый, әйтә белү. Китапханәчедән китап сорый, китапның нәрсә турында икәнен әйтә белү. Ничә китап укыганыңны әйтә, иптәшеңнән сорый белү. |
| **Көндәлек режим.**<br>Минем көндәлек режимым. | Вакытны әйтә, сорый белү. Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйли белү. |
| **Ашханәдә**<br>Без ашханәдә ашыйбыз. Ми нем | Ашханәдә нәрсә пешергәнне, ашаганны, нинди ашлар яратканны әйтә белү. Дустыңның нинди ризыклар яратканын |

| | |
|---|---|
| яраткан ашларым. Безгә кунаклар килә. Без табын әзерлибез. | сорый, ашханәгә бергә барырга тәкъдим итә белү. Кунакларны каршы ала, табынга чакыра белү. Табын әзерләү тәртибен әйтә, сорый белү. Ашханәдә дежур укучы хезмәтен сөйли белү. |
| **Без әти-әниләргә булышабыз**<br>Минем әти – әнием кем булып эшли? Без өйдә булышабыз. Без табын әзерлибез. | Әти-әниләрнең кем булып, кайда эшләвен, профессия исемнәрен әйтә белү. Өйдә үзең эшләгән эшләрне сөйли белү, иптәшеңә сорау бирә белү. Өй хезмәтендә катнашуыңны әйтә, эш куша белү. Табынны ничек әзерләү турында сөйли белү. |
| **Туган якка кыш килде**<br>Яңа ел бәйрәме. Һава торышы. Кышкы уеннар. Каникулда. | Бәйрәмнең сәгать ничәдә башланганын, Яңа ел бәйрәмендә нишләгәнне әйтә белү. Һава торышын сорый, әйтә белү. Кышкы уен төрләрен әйтә, уенга чакыра белү. Чаңгы ярышы турында сөйли белү. Каникулда кайда булганыңны әйтә белү. Геройларга характеристика бирә белү. Сюжетны үзгәртеп, яңа хикәя төзи белү. |
| **Без шәһәрдә (авылда) яшибез**<br>Татарстан – минем туган ягым. Татарстанда яшәүче милләтләр. Татарстан шәһәрләре. Без шәһәргә барабыз. Безнең авыл. | Татарстан шәһәрләренең, елгаларының атамаларын әйтә белү.Татарстанда яшәгән милләтләрне әйтә белү. Кайсы урамда яшәгәнеңне, нинди фатирда торганыңны, мәктәпкә нинди транспортта барганыңны сөйли белү. Шәһәр турында сөйли, үзең яшәгән шәһәрне, торган йортны сурәтли белү. Шәһәргә барырга чакыра белү. Нәрсәдә барганыңны, сәгать ничәдә барганыңны әйтә белү. Авыл табигате турында сөйли белү. Җәйге уен төрләрен әйтә белү. |
| **Әдәпле булыйк**<br>Әдәпле сөйләшү. Телефоннан әдәпле сөйләшү. Туган көнгә чакыру. Табын янында. Без бүләкләр бирәбез. | Телефоннан әдәпле сөйләшә белү. Туган көнгә әдәпле чакыра белү. Килгән кунакларны каршылый белү. Туган көнгә бүләк алып килгәнне әйтә, котлый белү. Бер-береңне табынга чакыра, кыстый, ашаганнан соң рәхмәт әйтә белү. 8 нче Март бәйрәмендә нинди бүләкләр бирү турында сөйләшү. Өлкәннәргә урын тәкъдим итә белү. Дустыңның авыруы турында, аңа ярдәм итү турында әйтә белү. |
| **Кечкенә дусларыбыз**<br>Дүрт аяклы дусларны сурәтләү, аларны карау. Минем яраткан песием. | Этләрнең кушаматын әйтә белү. Этләрне ничек караганны сөйли белү. Үзеңнең этең барлыгын, юклыгын, аны ничек караганны әйтә белү. Кешенең характер сыйфатларын әйтә белү. Песиләрнең тышкы кыяфәтен сорый, сөйли белү. Песиең барлыгын, юклыгын, аны ничек караганны сорый, әйтә белү. Кемнең нәрсә яратканын сорый һәм әйтә белү. |
| **Күңелле җәй, ямле җәй**<br>Без җәйне яратабыз. Ел фасыллары билгеләре. Җәй җитә. Без җиләккә барабыз. Безнең бакча. Җәйге ял. Сабантуй – зур бәйрәм. | Ел фасылларының билгеләрен әйтә белү. Җәй көне турында сөйли белү. Җәй көне укулар тәмамланганын әйтә белү. Предметларның билгеләрен чагыштырып әйтә белү. Урманга барганыңны, урманда җиләк җыйганыңны әйтә белү. Бер-береңне табынга чакыра, ашаганнан соң рәхмәт әйтә, азыкның тәмле икәнен әйтә белү. Бакчада нинди яшелчәләр үскәнен, бакчадагы эшләрне сорый, әйтә белү. Җәйге ял турында сөйли белү. Су керергә чакыра белү. Сабантуйда катнашу турында сөйләшү. |

**3 нче сыйныф**

Исем – сүз төркеме белән таныштыру.

Исемнең иялек килеше белән таныштыру.

**Чы/-че -** исем ясагыч кушымчалары белән таныштыру.

Сыйфат – сүз төркеме белән таныштыру.

Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар белән танышу.

Синоним һәм антоним сыйфатларны сөйләмдә куллану.

21дән 100 кадәр саннарны сөйләмдә куллану.

**Аннан соң** рәвеше һәм **һәр, һәркем, барлык,** алмашлыклары белән таныштыру.

Фигыль – сүз төркеме, аның хәзерге һәм үткән заман формалары белән таныштыру.
Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта күплектә 1,2,3 зат формалары белән таныштыру.
**–гына/-генә, -кына/-кенә** кисәкчәләре белән таныштыру.
**Янында, алдында, артында, турында** бәйлек сүзләрен сөйләмдә куллану.
**Ләкин, чөнки, шуңа күрә** теркәгечле җөмләләрне сөйләмдә куллану.
**Казан шәһәре, киемнәр кибете** – төзелмәләре белән таныштыру.
**Сәгать ничә? Сәгать ничәдә?** сорауларын һәм аңа җавапларны сөйләмдә куллана белү.

**Орфографик и орфоэпик минимум.**

Өйрәнелгән лексик берәмлекләрне орфоэпия нормаларына туры китереп әйтүне ныгыту.

Алынма сүзләрнең дөрес әйтелешен саклап, сөйләмдә кулланырга күнектерү.
Укучыларның язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерү эшен дәвам итү.
Ике бертөрле тартык янәшә килгән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу күнекмәләрен булдыру(китте, кайтты).
Янәшә килгән ике бертөрле тартык булган сүзләрне икеләтеп әйтергә өйрәтү.
**я, ю, е** хәрефләре, алар белдергән авазларның әйтелешен һәм язылышын истә калдыруны булдыру.
О, ө хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы.

**4 нче сыйныф**

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат, |
|---|---|
| **Яңа уку елы котлы булсын**<br>Яңа уку елы башлана.Уку-язу әсбаплары. Яңа уку елына әзерлек. Минем эш урыным. Без дәрестә. Без контроль эш эшлибез. | Беренче сентябрь көне ничек узуы турында сөйли белү. 1 нче сентябрь бәйрәме белән котлый белү. Яңа уку елына нинди уку-язу әсбапларын алу турында, уку-язу әсбапларының барлыгы, юклыгы турында әйтә белү. Татар теленең хәреф-аваз системасын сөйли белү. Дәрес әзерли торган эш урыны турында сөйли белү. Фикереңне дәлилли белү. Нинди предметтан контроль эш икәнен, дөрес эшләгәнне, эшләмәгәнне әйтә белү. Урамга чакыра, чыкмау сәбәбен аңлата белү. |
| **Кошлар һәм хайваннар дөньясында**<br>Йорт һәм кыргый хайваннар. Кыргый хайваннар турында кыскача мәгълүмат. | Йорт, кыргый хайваннарның исемнәрен атый, аларны сурәтли белү. Укылган текстлар буенча кыргый хайваннар турында кыскача мәгълүмат бирә белү. |
| **Кышкы уеннар**<br>Кышкы табигать. Кышкы уеннар. Кар бабай ясау. Яңа ел бәйрәменә барабыз. | Кышкы табигать турында сөйли белү. Кышкы уеннар турында сөйләшү. Дустыңны уенга чакыра белү, чыкмауның сәбәбен әйтә белү. Кар бабай ясауны сөйли белү. Дустыңны кар бабай ясарга чакыра белү. Яңа ел бәйрәменең кайчан башланганын, бәйрәмдә нишләгәнне әйтә белү. Гаиләдә бәйрәмне ничек каршылауны, нәрсәләр пешергәнне сөйли белү. |
| **Минем дусларым**<br>Минем дустым. Дуслар арасындагы мөнәсәбәтләр. Чын дуслык. | Дустың турында сөйли белү. Дус белән бергә нинди эшләр эшләү турында сөйләшү. Чын дус нинди булуын әйтә, рәслый белү. Дустыңа бүләк алуны, аның нинди икәнен әйтә белү. |
| **Дүрт аяклы дусларыбыз**<br>Дүрт аяклы дусларыбызның кыяфәтләре, гадәтләре. Дүрт аяклы дусларыбызга карата мөнәсәбәт. | Дүрт аяклы дусларыбызның кыяфәтләре, гадәтләре турында сөйли белү. Дүрт аяклы дусларыбызга карата үз мөнәсәбәтеңне белдерә белү. Дүрт аяклы дусларны карау, ашату, алар белән бергә уйнау турында сөйли белү. |
| **Яз килә**<br>Язгы табигать. 8 Март – әниләр бәйрәме. Мин әнигә булышам. Карга боткасы. | Язгы табигать турында сөйләшү, язның ни өчен ошаганын, ошамаганын әйтә белү. 8 нче март бәйрәме белән котлау яза, ничек котлаганыңны әйтә белү. Өй хезмәте турында сөйләшә, әти-әниләргә ярдәм итү турында сорый, әйтә белү. Өй хезмәтенә катнашуга карап, геройларга бәя бирү. Карга боткасы турында |

| | |
|---|---|
| | сөйли белү. |
| **Татарстан**<br>Татарстанның дәүләт символлары. Татарстанда яшәүче милләтләр. Без Казанга барабыз. Татарстан шәһәрләре. | Татарстанның символларын әйтә, сөйли белү. Татрстанда яшәгән милләтләрнең исемнәрен әйтә белү. Казанга баруың, анда нәрсәләр күрүең, Казанның нинди шәһәр булуы турында сөйли белү. Казанда Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы барлыгын әйтә белү. Россия, Татарстан шәһәрләрен атый, аларны сөйләмдә куллана белү. |

| | |
|---|---|
| **Матур җәй җитә**<br>Җәйге табигать. Җәйге ял. Җиләккә бару. | Җәйге табигать турында хикәяләп сөйли белү. Җәй көне кая барганыңны әйтә белү. Урманга, җиләккә бару турында сөйләшә белү. |

**4 нче сыйныф**

Исемнәрнең килеш белән төрләнешен сөйләмдә куллануны камилләштерү.
Тартымлы исемнәрнең күплек санда төрләнеше белән таныштыру.
Кушма, парлы исемнәрнең мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
Чагыштыру, артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
Вакыт рәвешләре (*бүген, иртәгә, кичә, иртән*) белән таныштыру.
**Монда, анда** рәвешләрен сөйләмдә куллану.
Тамыр, кушма, тезмә саннар белән таныштыру.
Мин, син зат алмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә сөйләмдә кулланышы.
**Кемдер, нәрсәдер** алмашлыклары белән таныштыру.
Билгесез үткән заман хикәя фигыльне барлыкта 3 затта сөйләмдә куллану.
**Кебек** бәйлеген сөйләмдә куллану.
**Кадәр, соң** – бәйлекләре белән таныштыру.
Ян бәйлек сүзен юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендә куллану.
**Уйнарга яратам, уйный башлады** – төзелмәләре белән таныштыру.

**Орфоэпик һәм орфографик минимум.**

1) Сүз басымы. Аны дөрес куя белүгә ирешү, рус сүзләре белән чагыштырып күрсәтү. Басымлы иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм матур язу күнекмәләре булдыру.
2) Басымның үзенчәлекле очракларын белү.
3) Сингармонизм законының асылын гамәли үзләштерү.
4) Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү.

**Татарская группа**

## ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Татар телен туган тел буларак укыту предметының уку материалы сөйләм эшчәнлеге төрләре (ишетеп (тыңлап) аңлау, сөйләү, уку, язу) һәм тел белеме бүлекләре буенча (фонетика һәм орфография, лексикология, сүз төзелеше һәм сүз ясалышы, морфология, синтаксис, орфография һәм пунктуация) төзелгән.

**Ишетеп аңлау.**

Ишеткән текстның эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирү, текстның төп мәгънәсен ачыклау максатыннан чыгып, әңгәмә оештыру.

**Сөйләү.**

Өйрәнгән сөйләм берәмлекләрен сөйләм ситуацияләрендә файдалану. Ана теленең орфоэпик һәм интонация нормаларын саклап, диалоглар һәм монологлар төзү. Уку процессында һәм сыйныфтан тыш чараларда төрле темалар буенча сөйләм этикеты үрнәкләрен куллану.

**Уку.**

Орфоэпия нормаларын саклап, логик басымнарны билгеләп укыган текстның эчтәлеген аңлау. Текстның темасын һәм төп фикерен аңлата белү.

**Язу.**

Авазларны, аваз тезмәләрен, иҗекләрне, сүзләрне һәм җөмләләрне язу күнекмәләрен булдыру. Әйтеп яздыру, өйрәнгән тема буенча текстны күчереп язу. Рәсем, видеоязма буенча, күргән яки ишеткән материалны өстәп, зур булмаган текст төзү.

**Фонетика.**

Авазлар һәм хәрефләр. Ишеткән сүздән сузык һәм тартык авазларны аеру. Аваз һәм хәрефләрнең санын һәм эзлеклеген билгеләү. Бер яки берничә хәрефе яки авазы белән аерылып торган сүзләрне чагыштыру. Сузык һәм тартык, калын һәм нечкә, басымлы һәм басымсыз, яңгырау һәм саңгырау авазларны аеру.

Иҗек. Сүзне иҗекләргә бүлү. Басымлы иҗекне билгеләү.

**Графика**.

Хәреф һәм аваз турында төшенчә. Сузык һәм тартык аваз хәрефләре. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны белдергән хәрефләр. Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрне чагыштыру, алардагы сузык авазларның әһәмияте. *Е - Ё, Ю, Я* хәрефләре. Калынлык *(ъ)* һәм нечкәлек *(ь)* билгеләре.

**Уку**.

Иҗекләп уку күнекмәләрен формалаштыру (сузык аваз хәрефләренә карап, сүзләрне калын һәм нечкә итеп әйтеп уку). Әдәби әйтелеш нормаларын саклап, тиешле тизлек белән иҗекләрне һәм бөтен сүзләрне салмак итеп уку. Сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне һәм кыска текстларны аңлап уку, гади җөмлә ахырындагы тыныш билгеләренә, җөмлә эчендәге тиңдәш кисәк, эндәш сүзләргә туры килгән интонация һәм паузаларга игътибар итеп уку. Зур булмаган текстны һәм шигырьләрне аңлап һәм сәнгатьле итеп уку күнекмәләрен шомарту.

Тулы сүзләрне укуга күчкәч, кайбер орфоэпик нормалар белән танышу.

**Язу**.

Язганда тиешле гигиена таләпләрен үтәү. Язганда, кул һәм бармак мускулларының җитез һәм ритмик хәрәкәт итүләренә ирешү. Баш һәм юл хәрефләренең язылышы. Гигиена нормаларын саклап, аерым хәрефләр, аларның кушылмасы, иҗек, сүз һәм җөмләләрне язу. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүз һәм җөмләләрне яздыру. Дөрес күчереп язу алымнарын һәм эзлеклелеген үзләштерү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, күчерү билгесе кую кебек график чараларның әһәмиятен аңлау.

**Сүз һәм җөмлә**.

Сүз һәм аның лексик мәгънәсе. Сүзләрнең мәгънә ягыннан төрләрен күзәтү. Сүзне һәм җөмләне аеру.

Җөмләдәге сүзләрне һәм аларның урнашу тәртибен үзгәртү.

**Орфография**.

Дөрес язу кагыйдәләре һәм аларның кулланылышы белән таныштыру:

2) сүзләрнең аерым язылышы;

3) о-ө хәрефләренең татар сүзләренең беренче иҗегендә генә язылуы;

4) җөмлә башындагы сүзне баш хәреф белән язу, җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләрен кую;

5) сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм юлдан-юлга иҗекләп, дөрес итеп күчерү.

**Сөйләм үстерү**.

Үзең укыган яки тыңлаган текстның эчтәлеген аңлау. Сюжетлы рәсемнәр, уйнаган уеннар һәм күзәтүләргә таянып, зур булмаган хикәяләр төзү.

**Тел системасын гамәли яктан үзләштерү**

**Фонетика һәм орфоэпия**.

